МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.02.2021 г. Казань № под-179/21

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 11 мартындагы 369/20 номерлы боерыгы белән расланган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 мартындагы 369/20 номерлы боерыгы

белән расланган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэминителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.3 пунктындагы 1.3.3 пунктчасының икенче абзацында «Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарында» сүзләреннән соң «һәм «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза - дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать. Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге Регламентның 2 нче, 3 нче кушымталарында китерелде;

алтынчы абзацта «муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.3 пунктындагы «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү, яши торган урыннары алмаштырылган очракта, Россия Федерациясе субъектында элеккечә яшәү урыны буенча исемлектән төшереп калдыру һәм аларны яңа яшәү урыны буенча Россия Федерациясе субъектының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү турында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 397 нче карары белән расланган Кагыйдәләр) 13, 34 пунктлары»

2.6 пунктындагы «Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктындагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында 3, 12 абзацларын төшереп калдырырга;

2.6 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Ятим бала туу турында таныклыкны (гражданлык актларын рәсмиләштерүнең бердәм дәүләт реестрында алырга мөмкин)»;

2.8 пунктындагы «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә), төгәлсезлеге һәм (яки) җитешсезлеге ачыкланган очракта, гаризадагы һәм тапшырылган документлардагы белешмәләрне тәгаенләштерү турында рәсми мөрәҗәгатьнең җибәрелүе дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезе булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

мөрәҗәгать итүче 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категорияләренең берсенә дә керми;

мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар тапшырылмаган яисә тулы күләмдә тапшырылмаган;

тапшырылган документларда ятим бала турында төгәл булмаган белешмәләр булган очракта.

Яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3.1 пунктының 1, 2 һәм 4 пунктчаларында каралган нигезләр булу»;

2.8 пунктындагы «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 04 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 12 пункты, 29 пункты;

«Ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1, 2, 4 пунктлары (алга таба - 159-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлеше (алга таба - 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы)»;

2.16 пунктындагы «Хезмәт күрсәтүне яисә таләпләрне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон; 210-ФЗ номерлы Федераль закон»;

3 бүлектә:

3.5 пунктта «8 эш көне» сүзләрен «19 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.1 пунктында «1 календарь көн» сүзләрен «1 эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентка кушымтаны (белешмә) яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкка кул куелган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинга йөкләргә.

Министр И.Г.Һадиуллин

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына
кушымта (белешмә)

## Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | 294-95-90 | mon@tatar.ru |
| Министр урынбасары<br>Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | 294-95-60 | mon@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге башлыгы<br>Васильева Венера Олеговна | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенең әйдәп баручы консультанты<br>Бегунова Светлана Григорьевна | 294-95-67 | Svetlana.Begunova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе башлыгы<br>(Бәдреев И.Ф.) | 264-77-29 | Ildar.Badreev@tatar.ru |
| Социаль өлкәдә хосусый-дәүләт партнерлыгын үстерү мәсьәләләре бүлеге башлыгы (Субаева Г.М.) | 264-76-77 | Gulshat.Subaeva@tatar.ru |